**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

№ 10 15.10.2015ел

Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл жирлеге Советының «җир салымы турында» 21.11.2008 ел, № 11 карарына үзгәрешләр кертү хакында (28.11.2009 ел, №13 үзгәрешләр белән)

Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Советының 21.11.2008 елгы 11 номерлы(28.11.2009 елгы 13 номерлы үзгәрешләр белән) җир салымы турында карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2 статьяның 4 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

«4) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, бакчачылык яки терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,092%»;

2. 3 статьяны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир участокларына карата 2 статьясының 6 пунктында билгеләнгән 1/30 күләмендә салым ташламасы (0,05 %) билгеләргә.

3. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан яки игълан ителгәннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

ТР Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге Советы Рәисе В.З.Николаев